**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 11 нче сыйныф**

*Үткәрү вакыты – 60 минут.*
*Максималь балл – 45.*

**I. Теоретик биремнәр. (7 балл)**

1. 1920-30 нчы еллар татар әдәбиятында мөрәҗәгать ителгән реализм иҗат юнәлешенә мөнәсәбәтле ике иҗат агымын аерып билгеләгез һәм исемнәрен язып куегыз. (4 балл)

2. Түбәндә аталган әсәрләрнең кайсылары 1930 нчы еллар татар әдәбиятына карый. (3 балл)
А) “Яшь йөрәкләр”
Б) “Көз”
В) “Тапшырылмаган хатлар”
Г) “Яшь гомер”
Д) “Агыйдел”

**II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (23 балл)**
1. Г.Исхакыйның “Көз” повестенда геройларның эш-гамәлләре аша нинди сыйфатлар хуплана, нindиләре тәнкыйтьләнә, кире кагыла? Аерып куеп, санап чыгыгыз. (10 балл)

2. Г.Исхакыйның “Көз” повестенда җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

3. Г.Исхакыйның “Көз” повестенда Гөлсем образын сурәтләү барышында кулланылган әдәби алымнарны билгеләп языгыз. (8 балл)

**III. Иҗади эш. (15 балл)**

Төрле тел-сурәтләү чараларын кулланып, үзегез теләгән бер күренешне детальләп сурәтләп языгыз.